ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.10.2016 Казан ш. № 3-1/э

«Татарстан республикасы территориясендә тармак оешмалары арасында үзара исәп – хисап ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә, 2015-2019 елларга индивидуаль тарифларны билгеләү турында» Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2014 елның 5 декабрендәге 3-9/э санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 26 мартындагы «Электр энергетикасы турында»гы 35-ФЗ федераль законына ярашлы рәвештә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 29 декабрендәге «Электр энергетикасында бәяләр (тарифлар) көйләү өлкәсендә бәяләр ясау турында»гы 1178нче карары белән, тарифлар буенча Федераль хезмәтнең «Бәяләрне (тарифлар) һәм (яки) аларның чик күләмнәрен билгеләү турында гаризаларны теркәү, карап тикшерүгә кабул итү һәм карап тикшерүдән баш тарту тәртибен күздә тоткан бәяләрне (тарифлар) һәм (яки) аларның чик күләмнәрен билгеләү регламентын һәм тарифларны дәүләти җайга салу өлкәсендә Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органы тарафыннан карар кабул итү формасын раслау турында» 2013 елның 28 мартындагы 313-э санлы, тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 2004 елның 6 августындагы «Ваклап сату (кулланучылар) базарында электр (җылылык) энергиясенә көйләнгән бәяләрне һәм тарифларны исәпләү буенча Методик күрсәтмәләрне раслау турында» 20-э/2нче әмере һәм 2012 елның 17 февралендәге «Кирәкле тулаем табышны озак вакытлы индексация ысулы кулланып, билгеләнгән электр энергиясен бирү хезмәтләренә тарифлар исәпләү буенча Методик күрсәтмәләрне раслау турында»гы 98/э боерыкларына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә, монополиягә каршы Федераль хезмәтнең 2016 елның 18 ноябрендәге СП/71305/16 санлы хатына таянып һәм 2016 елга билгеләнгән кирәкле тулаем

табышны һәм (яисә) бәяләрне (тарифлар) корректировкалау максатыннан чыгып, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан республикасы территориясендә тармак оешмалары арасында үзара исәп – хисап ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә, 2015-2019 елларга индивидуаль тарифларны билгеләү турында» Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2014 елның 5 декабрендәге 3-9/э санлы карарына (Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2015 елның 8 июнендәге 3-6/э санлы, 2015 елның 10 декабрендәге 3-10/э санлы карарларына керткән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«1. 2015 елның 1 гыйнварыннан 2019 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасы территориясендә тармак оешмалары арасында үзара исәп – хисап ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә индивидуаль тарифларны әлеге карарның 1 кушымтасы нигезендә, 1 кушытаның 21 пунктыннан һәм 3 кушымтаның 21 пунктыннан тыш календарь чорларына бүлеп билгеләргә.

Әлеге карарның 1 кушымтасындагы 21 пунктының һәм 3 кушымтасындагы 21 пунктының көче 2016 елның 1 декабрендә барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә тарала.»;

1 кушытаның 21 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 21 | «Түбән Кама нефтехим» гаммәви акционерлык җәмгыяте . «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте | 2015 | 30 234,19 | 25,54 | 0,06825 | 30 234,19 | 24,06 | 0,06677 |
| | | 2016 | 19 567,67 | 22,41 | 0,05015 | 5 332,17 | 96,03 | 0,10369 |
| | | 2017 | 30 906,84 | 25,54 | 0,06920 | 30 906,84 | 24,06 | 0,06772 |
| | | 2018 | 31 254,66 | 25,54 | 0,06969 | 31 254,66 | 24,06 | 0,06821 |
| | | 2019 | 31 613,80 | 25,54 | 0,07020 | 31 613,80 | 24,06 | 0,06872 |

»

3 кушытаның 21 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«

| | | | |
|---|---|---|---|
| 21 | «Түбән Кама нефтехим» гаммәви акционерлык җәмгыяте | 2015 | 75 803,76 |
| | | 2016 | 29 360,51 |
| | | 2017 | 77 490,25 |
| | | 2018 | 78 362,30 |
| | | 2019 | 79 262,75 |

»

2. Әлеге карар рәсми бастырылган көннән алып 10 көн үткәч үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов